***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА
**БИРЕМНӘРЕ**
(2024-2025 нче уку елы)
**7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 60**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге [**й**] авазының санын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Көн саен майлы ботка булмый.* (Мәкаль)
   а) 1
   ә) 2
   б) 3
   в) 4

2. Калын пары булмаган сузык авазны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [ү]
   ә) [и]
   б) [ә]
   в) [ө]

3. Җөмләдәге ябык иҗекләрнең санын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Ялкауга яңгыр иң беренче төшә.* (Мәкаль)
   а) 4
   ә) 5
   б) 6
   в) 7

4. Фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
   ***канат астына алу***
   а) качыру
   ә) урлау
   б) кочаклау
   в) яклау

5. Татар теленең үз сүзен билгеләгез. **(2 балл)**
   а) икмәк
   ә) дәфтәр
   б) кәбестә
   в) шагыйрь

6. Кушма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) аллы(гөлле)
ә) кура(җиләге)
б) кара(җиләк)
в) мал(туар)

7. Чама санын билгеләгез. **(2 балл)**

а) унау
ә) меңнәрчә
б) уникешәр
в) өч бөтен уннан бер

8. Юклык алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

а) алар
ә) сезнеке
б) нинди
в) һичкем

9. Җөмләдәге сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

*Бүгенге эшне иртәгә калдырма*. (Мәкаль)
а) сыйфат, исем, рәвеш, боерык фигыль
ә) сыйфат, исем, рәвеш, хикәя фигыль
б) рәвеш, исем, рәвеш, боерык фигыль
в) сыйфат, исем, исем, боерык фигыль

10. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**

*Оятсыз кеше өчен оятлының йөзе кызарыр.* (Мәкаль)
а) оятсыз
ә) кеше
б) оятлының
в) йөзе

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

Сузыкка тәмамланган иҗек – _____________ иҗек. [һ], [щ], [х], [ц] – _____________ саңгырау тартыклар. Исемнең иркәләү-_____________ кушымчасы – модальлек кушымча. Язылышлары төрле, әйтелешләре бертөрле булган сүзләр _____________ дип атала. Татар телендә _____________ килеш бар. Кыскартылма исемнәр сүзләрнең _____________ иҗекләреннән ясала ала. _____________ фигыль эш кушуны, үтенүне белдерә. Хикәя җөмлә ахырына _____________ куела.

### III. Башыгызны эшләтегез.

Сүзләрне дөрес итеп урнаштырып, ике мәкаль языгыз. **(4 балл)**

*эштән, эш, төннән, көн, караңгы, көләр, килә, соң, кичке, якты, көндезге*

________________________________________________________________

________________________________________________________________

### IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**

Мы готовим домашнее задание. Я повторяю старые слова, а подруга учит новые глаголы. Потом мы читаем недлинный текст, повторяем правила и пишем упражнения.

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

ИРТӘ БЕЛӘН

Җып-җылы, нурлы көн бүген.
**Бер кош юына тышта.**
Гаҗәпләнәм: үзе нәни,
Ә үзе нинди чиста!

Чирәмдәге чык суында
Коена да коена.
Аның чәчкән тамчылары
Җанлы сыман тоела.

Канатына ышкып ала
Нәни генә томшыгын.
Шифалы, тылсымлы диләр
Яландагы таң чыгын...

(*Галимҗан Гыйльманов*)

2.1. Сингармонизм законының рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл)** ____________________________________________

2.2. Тартыклар чиратлашуы күзәтелгән сүзләрне күчереп языгыз. **(3 балл)**

________________________________________________________________

2.3. ***Шифалы*** сүзнең синонимын языгыз. **(2 балл)** ______________________

2.4. Кушма сүзне күчереп языгыз. **(1 балл)** _____________________________

2.5. ***Җылы*** сыйфатының кимлек дәрәҗәсен языгыз. **(1 балл)** _____________

2.6. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмләнең хәбәрен языгыз. **(1 балл)**

________________________________________________________________

3. **“Канатлы дусларыбыз”** дигән темага 8-10 җөмләдән торган инша языгыз. **(12 балл)**

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________